ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

27.09.2019

№1443

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 нче елның 1 нче декрабендәге "2015-2021 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру «Муниципаль программасын раслау турында» 1356 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының 2018 нче елның 29 нчы июнендәге «2018-2020 елларга коррупциягә каршы көрәш милли планы турында» 378 нче санлы Указын, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 нчы елның 4 нче маендагы 34 - ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 нче елның 19 нчы июлендәге “2015-2020 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” 512 нче номерлы карарын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2015-2021 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 нче елның 1 нче декабрендәге 1356 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемен "2015-2021 еллар» сүзләрен «2015-2022 еллар" сүзләренә алмаштырырга»;

1.2. Карарның 1 пунктында «2015-2021 еллар» сүзләрен «2015-2022 еллар» сүзләренә алмаштырырга.

2. “2015-2022 елларга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру” муниципаль программасын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына “2015-2022 елларга Алабуга муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру»программасын гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны алдан карарга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче урынбасары Л.Ф. Нургаянов